ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.04.2020 Казан шәһәре № 52

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2018 елның 11 июлендәге 70 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны электрон рәвештә формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында» 2018 елның 11 июлендәге 70 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.4 пунктның «г» пунктчасындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш) яисә гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документлар һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр;».

Рәис С.Е. Иванов